| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2017 Казан ш. № 10-25/кс

Су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 13.10.2017 № 10-25/кс
карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | Җыентык суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр |
| | Лаеш муниципаль районы | | |
| 1 | «Коммуналь сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 25,82 | |
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге | | |
| 2 | «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | | 5,64 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге